# Аллаһның Үз мәхлукларыннан югарыда булуы

علو الله على خلقه

اللغة التترية

ALSARHAAN.COM

سؤال:
بعض الناس يقول: إن الله فوق السماوات وبعض العلماء يقول: إن الله ليس له مكان فما القول الصحيح في هذه المسألة؟

**Сорау:**
**Кайбер кешеләр Аллаһ күкләр өстендә дип әйтәләр, ә кайберләре Аллаһның урыны юк диләр, шушы сорауда чынбарлык нидә?**

الجواب: استدل أهل السنة على علو الله تعالى على خلقه علواً ذاتيًا
بالكتاب والسنة والاجماع والعقل والفطرة

**Җавап: Сөннәт әһелләре Коръәнгә, Сөннәткә, галимнәрнең бердәм фикеренә, акылга һәм кешенең фитри иманына дәлилләнеп Бөек Аллаһ Үзенең заты белән барлык мәхлуклардан да өстен, югары дип әйтәләр.**

فإما الكتاب فقد تنوعت دلالته على علو الله سبحانه على خلقه.
**Коръәндә исә Аллаһның Үз мәхлукларыннан югары булуына күп төрле дәлилләр бар:**

فتارة بذكر العلو وتارة بذكر الفوقية وتارة بذكر نزول الأشياء من وتارة بذكر صعودها إليه ، وتارة بكونه سبحانه في السماوات.

**кайбер чакта Аллаһның югарыда булуы, кайвакыт – "өстә" – дип , кайбер чакта кайбер нәрсәләрнең аска төшүе, я инде Аңа нәрсәнең дә булса күтәрелүе, һәм шулай ук Аның күктә булуы искә алына.**

فالعلو في مثل قوله :

سبح اسم ربك الأعلى،

**Һәм Аллаһның югарыда булуына: «Иң югарыда булган Раббыңның исемен данла»,– дигән аят;**

والفوقية في مثل قوله :

وهو القاهر فوق عباده.

**Аллаһның барлык мәхлуклардан да өстә булуына: «Һәм Ул Аллаһ бар нәрсәне дә билэп алучы. Һәм Ул Үзенең коллары өстендә» – дигән аят;**

ونزول الأشياء منه في مثل: إنا نحن نزلنا الذكر .

**Һәм кайбер нәрсәләрнең аска төшерелүенә: «Хакыйкатьтә, Без искәртмә төшердек», – дигән аят;**

وصعود الأشياء إليه في مثل قوله:

إليه يصعد الكلم الطيب والعمل الصالح يرفعه.

**Һәм Аңа нәрсәнең дә булса күтәрелүенә: «Аңа яхшы сүзләр күтәрелә һәм Ул изге гамәлләрне югарыга күтәрә»,– дигән аят;**

وكونه في السماء في مثل قوله :

أأمنتم من في السماء أن يخسف بكم الأرض.

**Шулай ук Аллаһның күктә булуына – «Әллә сез күктә булган Аллаһ җирне сезне йотырга мәҗбүр итмәс дип ышанасызмы?», – дигән аятләр дәлил булып торалар.**

وأما السنة فمثل: رفع يديه صلى الله عليه وسلم إلى السماء في الدعاء كما ورد في عشرات الأحاديث ،

**Ә инде Пәйгамбәребезнең сөннәтендә булган дәлилләргә килгәндә – Пәйгамбәребезнең ﷺ күккә таба кулларын күтәреп дога кылуы унлаган хәдисләрдә хәбәр ителә.**

ومثل ما جاء في حديث الجارية التي قال لها النبي صلى الله عليه وسلم اين الله ؟! قالت : في السماء

فقال : من أنا؟ !

قالت: أنت رسول الله.

فقال لصاحبها: اعتقها فإنها مؤمنة.

فهذه أَمةٌ غير حُرة لا تملك من أمر نفسها شيئا.

تعلم أن ربها في السماء

**Яшь кол хатын турында килгән хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ аңардан: "Аллаһ кайда?",- дип сорагач - Ул: "Күктә",- дип җавап кайтарган. Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ :"Мин кем?",- дип сорагач - Ул: "Син Аллаһның илчесе",- дип җавап биргән. Шулчак Пәйгамбәребез ﷺ аның хуҗасына: "Җибәр аны, хакыйкатьтә, ул иман китерүче",- дип әмер иткән.**
**Шулай итеп укый да, яза да белмәгән )надан(, үз-үзенә дә хуҗа булмаган кол хатын Раббысының күктә икәнен белә.**

وضُلال بني آدم ينكرون أن الله في السماء

**Ә ялгышкан адашкан Адәм балалары Аллаһ күктә икәнне инкарь итеп:**

ويقولون: أنه لا فوق ولا تحت ولا يمين ولا شمال.

**"Аллаһ өстә дә түгел, аста да түгел, уңда да, сулда да түгел",– ә киресенчә –**

بل يقولون: أنه في كل مكان.

**"Ул бөтен җирдә",– дип әйтәләр.**

وأما دلالة الإجماع فقد أجمع السلف على أن الله تعالى بذاته في السماء.

**Шулай ук галимнәребезнең бердәм фикеренә килгәндә, сәләфләр бер тавыштан Аллаһ үз заты белән күктә дип әйттеләр.**

وقد نقل أقوالهم أهل العلم كالذهبي رحمه الله في كتابه العلو للعلي الغفار.

**Һәм бу  галимнәрнәрнең сүзләре Имам әз-Зәхәби шикелле галимнәребезнең "Әл-гүлү лилГәлийиль-Гаффәр" дигән китабында да хәбәр ителә.**

واما دلالة العقل فان العلو صفة كمال باتفاق العقلاء.

**Әмма акыл дәлилләренә килгәндә, барлык акыл ияләре дә  югарылыкның камиллек сыйфаты булуынраслыйлар.**

واذا كان كذلك وجب أن يكون ثابتا لله.

**Шулай була калса, бу сыйфат Аллаһка бәйле булырга тиеш.**

لأن كل صفة كمال مطلقة فهي ثابتة تعالى.

**Чөнки барлык абсолют тулы, камил булган сыйфат та Аллаһныкы булырга тиеш.**

وأما دلالة الفطرة فأمر لا يمكن المنازعة فيه ولا المكابرة.

**Табигый фитрага килгәндә, Аллаһның күктә икәнлегендә бернинди дә шик һәм каршылык булуы мөмкин түгел.**

فكل انسان مفطور على أن الله تعالى في السماء

**Һәм һәрбер кешенең фитри иманында Аллаһ күктә булуы билгеләнгән.**

ولا أدل على ذلك من إنسان تصيبه المصيبة فيتوجه إلى الله تعالى لدفع فإن قلبه حينئذ ينصرف إلى السماء لا إلى أي جهة أخرى.

**Шуның өчен кеше белән берәр хәл килеп чыкса, ул шушы бәладән Аллаһка мөрәҗәгать итеп йөрәге белән күккә юнәлә, башка бер якка да түгел.**

بل العجيب أن الذين ينكرون علو الله على خلقه لا يرفعون أيديهم في الدعاء إلا إلى السماء.

**Һәм Аллаһның югарыда булуын инкарь иткән кешеләр дә дога кылганда кулларын күккә таба күтәрүләре бик гаҗәеп күренеш.**